ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**24 июнь 2023 ел** **№ 100**

**Красносельский авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 мартындагы 27 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 мартындагы 27 нче номерлы (2019 елның 22 мартындагы 117 нче номерлы Совет карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 нче пунктның в) пунктчасында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 13 нче пунктта «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

1.3. 16 нчы пунктның 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш Муниципаль вазыйфаны биләүче затларның үз чыгымнары турында мәгълүмат бирмәве, яки тулы булмаган мәгълүмат бирү, яки үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүмат бирү яки федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирмәү яки тулы булмаган мәгълүмат бирү, яки хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүмат бирү, әгәр мондый

мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, ул муниципаль вазифаны биләүче затларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алмаштырыла торган (биләгән) вазифадан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко